КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 17 июль г.Казань № 602

«Мин күкне сайлыйм!» авиация бәйрәмен үткәргәндә Казан шәһәре чикләрендәге су объектларыннан файдалану турында

Россия Федерациясе Су кодексының 6 һәм 25 статьялары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында кешеләр тормышын саклау кагыйдәләрен раслау турында» 2009 ел, 23 апрель, 256 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында кешеләр тормышын саклау кагыйдәләренең 1.3 нче пункты нигезендә, «Мин күкне сайлыйм!» авиация бәйрәмен үткәргәндә кешеләр тормышы иминлеген тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

2020 елның 25 июлендә 12 сәгать 00 минуттан 20 сәгать 00 минутка кадәр Казансу елгасында, Миллениум күпереннән Кремль дамбасына кадәр, азсыешлы судноларны, шулай ук җилкәнле, ял итү, спорт судноларын (гидроциклларны, байдаркаларны, ишкәкле көймәләрне кертеп) файдалануны тыярга;

бу пунктның икенче абзацында күрсәтелгән судноларны файдалануны тыю «Мин күкне сайлыйм» авиация бәйрәмен әзерләүгә һәм үткәрүгә җәлеп ителгән судноларга кагылмый.

2. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына:

бу карар белән билгеләнгән тыюны үтәү максатларында Казансу елгасы акваториясендә көчләрнең һәм чараларның кизү торуын тәэмин итәргә;

халыкка кертелә торган тыю турында, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чаралары аша мәгълүмат бирү эшен оештырырга.

3. Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенә бу карар белән билгеләнгән тыюны үтәү максатларында көчләрнең һәм чараларның кизү торуын тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин